Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Урахча авыл җирлеге составына керүче
Урахча авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

19 ноябрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Урахча авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Урахча авылындагы Совет, Ленин, Гагарин , Мельничный Починок авылындагы Давыдов , Киров, Мәктәп, Наратлы авылындагы Карбышев урамнарында юлларны төзекләндерү өчен;

-Урахча авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен су суырткыч җайланмасы сатып алу өчен;

- кышын Уракчы авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап торуга

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 283 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 179 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 179 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Урахча авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Урахча авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Урахча авылындагы Совет, Ленин, Гагарин , Мельничный Починок авылындагы Давыдов , Киров, Мәктәп, Наратлы авылындагы Карбышев урамнарында юлларны төзекләндерү өчен;

-Урахча авылында авылындагы суэтем башнясына тирәнлек насосы сатып алуга;

- кышын Урахча авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап торуга

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гараев Ф.М.

Урахча авыл җирлеге башлыгы: Гараев Ф.М